ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОРУССКО-
МАМАТКОЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

02.11.2020 с. Старое Русское Маматкозино 21

Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында 2020нче елның 16нчы ноябренә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы:

- Татар Мәмәтхуҗасы авылы зиратына вак таш сатып алу һәм төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Татар Мәмәтхуҗасы авылы, Солнечная урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге
башлыгы В. В. Никитушкин